

# ЧИШМӘ БАШЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

№2 2025ел
октябрь

*Ата -аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы*

- КӨЗГЕ СЫНАМЫШЛАР
- ӨЛКӘННӘР КӨНЕ
- ЯҢАЛЫКЛАР!
- ӘТИЛӘР КӨНЕ!
- СӨМБЕЛӘ

## КӨЗГЕ СЫНАМЫШЛАР

- Кояш батканда аяз булып, төньяктан салкынча җил булса, кырау төшәр.
- Көз озын килсә, яз соң килер.
- Көзнең ахырында вак кына түгәрәк-түгәрәк боз яуса, кыш суык булыр.
- Урманда чикләвек күп булса, кыш кырыс булачак.
- Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.
- Кыр казлары көзен киткәндә түбәннән очып китсәләр, кар тиз булыр.
- Көз көне кошлар түбән очса, кыш – салкын, югары очса, кыш җылы килә.
- Тычканнар кибән астында торса, көз коры булыр.



## ӨЛКӘННӘР КӨНЕ

Ел саен 1 октябрьдә илебез Халыкара өлкәннәр көнен билгеләп үтә. Бәйрәмнең көз фасылына туры килүе очраклы түгел. Алтын көзге чорда без бөтен көчен һәм белемен халкына багышлаган, яшь буынга якты тормыш бүләк иткән кешеләрне хөрмәтлибез.



Бу бәйрәм – өлкән буынга җәмгыять тарафыннан олы хөрмәт күрсәтү. Халыкара өлкәннәр көне – олы буыныбызга тирән хөрмәт белдерү һәм намуслы хезмәтләре, зур тормыш тәҗрибәсе, игелеге, зирәклеге өчен җылы рәхмәт сүзләре әйтү өчен мөмкинлек бирә торган бәйрәм.
Бәйрәмнең кайсы да җанга ял алып килә.
Арча сигезенче номерлы балалар бакчасында төрле елларда эшләп лаеклы ялга чыккан тәрбиячеләрне, хезмәткәрләрне бәйрәм белән котладык.

Халыкара өлкәннәр көне уңаеннан сезгә иң җылы, ихлас котлауларыбызны җиткерәбез. Без сезне, хезмәтегезне ихтирам итәбез, рәхмәтләребезне белдерәбез. Һәммәгезгә дә нык сәламәтлек, иминлек, озын гомер, күңел тынычлыгы, якын кешеләрегезнең мәхәббәтен, игътибарын һәм хөрмәтен тоеп, озак яшәвегезне телибез. Бәйрәм белән!

# ЯҢАЛЫКЛАР!



- Яшь буынга белем һәм тәрбия системасына керткән зур өлеше, күпьеллык намуслы хезмәте өчен "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе белән бакчабызның тәрбиячесе Сиразиева Зульфия Тимергалиевна бүләкләнде. Котлыйбыз!




Бакчабызда тәрбияләнүчеләр тәрбиячеләре белән бергә тимер юл вокзалына экскурсия ясады-лар. Тимер юл вокзалы болдырында балаларны тимер юл станциясе хезмәткәрләре каршы алды. Алар Вокзал хезмәткәр-ләренең эш үзенчәлекләре турында сөйләделәр, тимер юл транспорты төрләре белән таныштырдылар, бина буйлап экскурсия уздырдылар. Үткәрелгән экскурсия нәтиҗәсендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар үз-үзләрен тоту кагыйдәләре турында белемнәр алдылар.

- Безнең балалар бакчасында Россия Федера-циясе Гражданнар оборонасы көненә багыш-ланган Бөтенроссия кур-кынычсызлык мәдә-нияте ачык дәресе уз-ды. Балалар белән әң-гәмәләр үткәрелде, куркыныч хәлләр белән презентацияләр күрсәтелде, алардан балалар тормышыбызда куркыныч-сызлыкның мөһим-леге турында белделәр.






- Бакчабызда Татарстан Республикасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы чемпионнары фестивале узды. ГТО уеннары — командалы ярыш. «ГТО уеннары» команда ярышларында җиңүчеләрне команданың барлык катнашучылары тарафыннан барлык этапларны узуга сарыф ителгән иң аз вакыт буенча билгеләделәр.Командалар дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнде. Фестиваль нәтиҗәләре буенча безнең команда мактаулы 2 урынны яулады!!!!

- Сәламәтлек көне кысаларында өлкән һәм әзерлек төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр «Казансу» футбол манежына экскурсия ясадылар. Экскурсиянең максаты-шәһәребезнең спорт объекты белән танышу һәм балаларны актив сәламәт яшәү рәвешенә тарту. Футбол манежына Экскурсия-үзеңне чын футболчы итеп тою өчен гаҗәеп шанс, ә шулай ук бу киләчәккә зур тәҗрибә. Тренер Ренат Рашшатович үзенең яшь футболчылары белән балалар бакчасында тәрбия-ләнүчеләр өчен мавыктыргыч мастер - класс үткәрде, анда футбол нигезләре белән таныштырдылар һәм күнегүләр күрсәттеләр. Экскурсияне оештырган өчен директор Айрат Фиркат улына рәхмәтебезне белдерәбез.





- Бакчабызда мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүчеләр арасында татар теленнән олимпиада булып узды. Балалар үзләренең, татар теленнән белем-нәрен күрсәттеләр. Олимпиада барышында (урта-сында) физминуткага Шүрәле белән Былтыр керде. Алар балалар белән уеннар уйнадылар.Җиңеп чыккан ике бала район күләмендә узачак олимпиадада катнашып бакчабызның данын яклаячаклар. Аларга уңышлар теләп калабыз!

# ӘТИЛӘР КӨНЕ!

*Зур шатлык күңелебездә,*
*Ал кояш күгебездә.*
*Барыгыз да беләсездер-*
*Әтиләр көне бездә.*

Россиядә көз көне әтиләр көнен — җылы гаилә бәйрәмен билгеләп үтәләр. Ул безгә гаиләдә әтиләрнең мөһим ролен искә төшерә. Президент Владимир Путин Указы белән 2021 елда бәйрәм гаиләдә һәм җәмгыятьтә әти статусын ныгыту өчен гамәлгә куелган. Шуннан бирле аны ел саен октябрьнең өченче якшәмбесендә бәйрәм итәләр.

Безнең балалар бакчасында әтиләр көненә багышланган искиткеч күңел ачу чаралары узды! Бу чаралар барлык катнашучылар өчен дә чын бәйрәмгә әверелде. Әтиләр балалар белән бергә төрле эстафета һәм конкурсларда бик теләп катнаштылар. Җитезлек, тизлек һәм команда рухында ярыштык! Һәр бирем елмаю һәм соклану уятты, ә дустанә атмосфера онытылмас истәлекләр тудырды. Барлык әтиләргә дә актив катнашулары һәм уңай хис-кичерешләре өчен рәхмәт! Бу көн сезнең һәм балаларыгыз өчен озак вакытлар истә калыр дип өметләнәбез.









# СӨМБЕЛӘ

Татар халкының иң борынгы бәйрәмнәре арасында «Сөмбелә» исемле Уңыш бәйрәме аерым урын алып тора. «Сөмбелә» көнендә, көз көне көн белән төн тигезләшкәндә, бәйрәм итәләр. Бу чорда уңыш җыеп алынган, көзгә иген чәчү эшләре дә төгәлләнгән була. Бу – татар халкының хезмәткә багышланган милли бәйрәме. Әлеге бәйрәмнең тамырлары бик еракка китә, хәтта бабаларыбыз да, барлык кыр эшләренең тәмамлануына шатланып, аны зурлап үткәргәннәр. Сөмбелә бәйрәмендә кешеләр кырдагы озак һәм катлаулы эшләрдән соң ял иткәннәр.

Бу бәйрәм белән матур легенда бәйле: авылда иң шаян, телгә оста, чәчләре аксыл кызны сайлап алганнар, аны милли киемгә төреп, кыр яки мәйданга алып чыкканнар һәм анда аңа алдагы кышлау турында, киләсе елның ничек булуы, игенче нәрсә көтәсе турында катлаулы сораулар биргәннәр. Сөмбеләнең алдан күрүләренә хәтта аксакаллар да игътибар иткәннәр:"Синең сүзең хак булсын!" дип алкышлап куәтли торган булганнар. Сөмбеләнең сары чәчле булуы мөһим саналган, чөнки бу көзнең һәм алтын башакларның билгесе булган.

Безнең балалар бакчасында да 20 октябрь көнне, кечкенәләр төркемендә "Хуш киләсең, ямьле Көз" дигән бәйрәм узды. Балалар рәхәтләнеп биеделәр, җырладылар, күңел ачтылар. Кунакка Сөмбелә һәм Уңыш бабай килде. Алар балалар белән бергәләшеп "Кояш һәм яңгыр", "Өлгерләр ярышы", " Кем тизрәк чүпләр? " уенын уйнадылар. Үзләренең инде зур үскәннәрен күрсәтеп, "Күрсәт әле үскәнем" җырлы-биюле уенын биеп күрсәттеләр. Бәйрәм күтәренке рухта тәмамланды.



*Баш мөхәррир -- татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы*
*Мөхәррир урынбасары - логопед Шәрипова Алсинә Хаҗиәхмәт кызы*